РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ ЮЛБАТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422077, Республика Татарстан,
с. Юлбат, ул. Г.Тукая, 57
тел. (84362) 43-7-22

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЮЛБАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422077, Татарстан Республикасы,
Юлбат авылы, Г.Тукай урамы, 57 йорт
тел. (84362) 43-7-22

e-mail: Ulbat.Sab@tatar.ru

20.09.2019 № 19

РЕШЕНИЕ КАРАР

Татарстан Республикасы Юлбат авыл җирлеге Советының 2009 елның 21 декабрендәге 23 номерлы «Юлбат авыл җирлеге Советы регламентын раслау турында " карары белән расланган Юлбат авыл җирлеге Советы Регламентына үзгәрешләр кертү хакында»

ТР Саба районы прокуратурасының 10.09.2019 елгы №02-01-20-19 хаты, Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Уставына нигезендә, Юлбат авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. "Юлбат авыл җирлеге Советы регламентын раслау турында" 2009 ел, 21 декабрь, 23нче карары белән расланган Юлбат авыл җирлеге Советы Регламентына кертергә:

1.1. Регламентның 6 бүлеген түбәндәге эчтәлекле 34.1 статья белән тулыландырырга:

"34.1 Статья.

1. Юлбат авыл җирлеге башлыгы, район прокуроры, шулай ук Юлбат авыл җирлеге Уставы, закончалык белән вәкаләтле вазыйфаи затлар, Советның ачык һәм ябык утырышларында катнашырга хокуклы.

2. Советның ачык утырышларында Юлбат авыл җирлегендә яшәүчеләр һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала.

3. Башкарма комитет хезмәткәрләре Совет тарафыннан алар карамагына караган мәсьәләләрне караганда ачык утырышларда катнашырга хокуклы.

4. Әгәр гомуми депутатларның күпчелеге тарафыннан хупланса, Совет җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының утырышта катнашуын таләп итәргә хокуклы.

Катнашу турында таләп, утырышка кадәр өч көннән дә соңга калмыйча, Совет утырышына чакырылучы вазыйфаи затка утырышның көне, вакыты, урыны, утырышка куелган сораулар турында Совет рәисе тарафыннан хәбәр ителергә тиеш.

5. Утырышны ачар алдыннан, Совет рәисе Совет депутатлары булып тормаучы, утырышта катнашучы затлар турында игълан итә.

6. Утырышка чакырылган һәм катнашучы затлар Совет эшенә тыкшынырга хокуклы түгел. (чыгыш ясарга, белдерү эшләргә, хуплау яки ризасызлык белдерергә)

7. Совет карары нигезендә, чакырылганнарга әлеге Регламент кысаларында чыгыш ясау өчен сүз бирелергә мөмкин."

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/ulbat адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырырга.

3. Карар рәсми бастырып чыгарган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Юлбат авыл җирлеге башлыгы: Т.Р. Шәмсиев